| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2023 г. Казань № 794-190/кс-2023

2024 елга Менделеевск муниципаль районы «Шифалы су (целебная вода) - Ижминводы» шифаханәсе һөнәри берлекләренең хосусый дәвалау-профилактикалау учреждениесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2023 №60-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә Менделеевск муниципаль районы «Шифалы су (целебная вода) - Ижминводы» шифаханәсе һөнәри берлекләренең хосусый дәвалау-профилактикалау учреждениесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы Менделеевск муниципаль районы «Шифалы су (целебная вода) - Ижминводы»

шифаханәсе һөнәри берлекләренең хосусый дәвалау-профилактикалау учреждениесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2023 № 794-190/кс-2023
карарына кушымта

2024 елга Менделеевск муниципаль районы «Шифалы су (целебная вода) - Ижминводы» шифаханәсе һөнәри берлекләренең хосусый дәвалау-профилактикалау учреждениесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | | | | | | | |
| | | изоляциялəнгән терәкләр белән | | изоляцияләнмәгән терәкләр белән | | изоляциялəнгән терәкләр белән | | изоляцияләнмәгән терәкләр белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | | | |
| | Менделеевск муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «Шифалы Су (целебная вода) – Ижминводы» шифаханәсенең һөнәри берлекләр дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе | | | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 142,46 | 132,52 | 152,62 | 142,46 | 165,70 | 154,75 | 178,84 | 167,45 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 118,72 | 110,43 | 127,18 | 118,72 | 138,08 | 128,96 | 149,03 | 139,54 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге